**Югары Чура авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**22 гыйнвар, 2024 ел** **№ 2**

Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура авылында «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары-Чура авыл җирлеге Уставының 20 статьясы нигезендә Югары-Чура авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 05 февраленә 15 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Югары-Чура авылы, Мәктәп урамы, 34 йорт адресында урнашкан авыл мәдәният йортында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Югары Чура торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Югары Чура авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә Сез ризамы:

2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны кабул итәргә: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Югары Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк

затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 3700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы — В.Н. Андреев